ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2024 г.Казань № 530-114/кс-2024

Зеленодольск муниципаль районы «ТатСтройКа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2025 елга салкын су транспортлауга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 17.12.2024 ел, №34-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Зеленодольск муниципаль районы «ТатСтройКа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «ТатСтройКа» ҖЧҖ) өчен салкын су транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә «ТатСтройКа» ҖЧҖ су белән тәэмин итү өлкәсендәге җитештерү программасын расларга.

3. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТатСтройКа» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары

нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2024 № 530-114/кс-2024
карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТатСтройКа» ҖЧҖ өчен
2025 елга салкын су транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Салкын суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | |
| 1 | «ТатСтройКа» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 3,12 | 5,21 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2024 № 530-114/кс-2024
карарына 2 нче кушымта

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Оешманың җитештерү программасы** | | | | |
| **1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты** | | | | |
| **Җайга салынулы оешма** | «ТатСтройКа» ҖЧҖ | | | |
| Урнашкан урыны | 422527, ТР, Зеленодольск районы, Осиново авылы, Светлая урамы, 10А, офис 3 | | | |
| **Җайга салуның вәкаләтле органы** | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | |
| Урнашкан урыны | 420015, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й. | | | |
| **Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры** | башлана | 01.01.2025 | тәмамлана | 31.12.2025 |

**2 нче бүлек. Су бирү күләме/Кабул ителгән су**

1ХВС - Салкын суны транспортлауга тариф - су белән тәэмин итү

| **№** | **Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
|---|---|---|---|
| | | | **2025** |
| 1 | Читтән алынган су күләме | мең м3 | 0,00 |
| 2 | Челтәргә бирелгән су | мең м3 | 0,00 |
| 3 | Су югалту күләме | мең м3 | 370,00 |
| 4 | Су җибәрелгән, барлыгы | мең м3 | 70,00 |
| 5 | Предприятие ихтыяҗларына тотыла торган су күләме | мең м3 | 300,00 |
| 6 | Кулланучыларга су җибәрү (сату), барлыгы, шул исәптән: | мең м3 | 0,00 |
| 6.1 | су белән тәэмин итүнең башка оешмаларына | мең м3 | 300,00 |

**3 нче бүлек. Җитештерү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме**

| **№** | **Күрсәткеч** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
|---|---|---|---|
| | | | **2025** |
| 1 | Транзит оешмасының кирәкле тулай кереме | мең сум | 1 249,61 |
| 2 | Гарантияләүче оешманың (ГО) (УТР) агымдагы чагыштырма чыгымнары | мең сум/шарт.км | 419,53 |
| 2.1 | су/агып төшүче суларны транспортлау эшчәнлеге төренә кертелгән ГО агымдагы чыгымнары | мең сум | 495,05 |
| 2.1.1 | шул исәптән электр энергиясенә чыгымнар | мең сум | 0,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.2 | 2024 елга куллану бәяләре индексы | % | 8,00 |
| 2.3 | 2025 елга куллану бәяләре индексы | % | 5,79 |
| 2.4 | чагыштырма зурлыкларда билгеләнгән ГО челтәренең озынлыгы | шарт.км | 1,18 |
| 3 | Транзит оешма челтәренең озынлыгы | шарт.км | 2,979 |
| 3.1 | челтәрләрнең факттагы озынлыгы | км | 6,401 |
| 4 | Амортизациягә чыгымнарның норматив дәрәҗәсе | мең сум/шарт.км | 0,000 |
| **4 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы** | | | |
| **№** | **Чараның аталышы** | **план чоры** | |
| 1 | Җитештерү программасын гамәлгә ашыру кысаларындагы чаралар каралмаган | | |
| **5 нче бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре** | | | |
| **№** | **Күрсәткеч** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
| | | | **2025** |
| 1ХВС - Салкын суны транспортлауга тариф - су белән тәэмин итү | | | |
| 1 | Эчә торган суның сыйфат күрсәткечләре | | |
| 1.1 | Дпс – Су белән тәэмин итү чыганакларыннан, суүткәргеч станцияләреннән яисә үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасының башка объектларыннан бүлү суүткәргеч челтәренә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган эчәр су пробаларының эчәр су сыйфатын производство тикшереп торуы нәтиҗәләре буенча алынган пробаларның гомуми күләмендә бирелә торган эчәр су пробалары өлеше | % | - |
| 1.2 | Дпрс – Бүлүче суүткәргеч челтәрендә эчәргә яраклы суның сыйфатын производство тикшереп торуы нәтиҗәләре буенча алынган пробаларның гомуми күләмендә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган эчәргә яраклы су пробалары өлеше | % | - |
| 2 | Су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы һәм өзлексезлеге күрсәткечләре | | |
| 2.1 | Пн – Салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы объектларындагы аварияләр, зарарланулар һәм башка технологик хокук бозулар нәтиҗәсендә салкын су белән тәэмин итү буенча салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың йөкләмәләрен үтәү урыннарында салкын су белән тәэмин итү шартнамәсендә, бердәй су белән тәэмин итү һәм су түгү шартнамәсендә яисә салкын су ташу шартнамәсендә билгеләнгән өзеклекләр саны салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың су белән тәэмин итүләре, елга суүткәргеч челтәренең озынлыгын исәпләп, бер елга | бер./км | |
| 3 | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | |
| 3.1 | Дпв – суүткәргеч челтәренә бирелгән суның гомуми күләмендә суны транспортировкалаганда үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларында су югалтулар өлеше | % | 18,92 |
| 3.2 | Урп – Эчә торган суны транспортлауның технологик процессында кулланыла торган электр энергиясенең транспортлана торган эчә торган су күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы | кВт*сәг/куб.м | - |
| **6 нчы бүлек. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләренең һәм җитештерү программасын гамәлгә ашыру чыгымнарының аның гамәлдә булу чоры дәвамында** | | | |

<table>
<tr><td colspan="4">үзгәреш динамикасын чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла торган җитештерү программасының нәтиҗәлелеген исәпләү</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2">Күрсәткеч</td><td rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td>Планлаштырыла торган чор күрсәткече зурлыгы</td></tr>
<tr><td>2025</td></tr>
<tr><td colspan="4">1ХВС - Салкын суны транспортлауга тариф - су белән тәэмин итү</td></tr>
<tr><td></td><td>Үзгәреш динамикасын чагыштыру</td><td>%</td><td>Ышанычлылык, сыйфат һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре үзгәрешсез билгеләнә</td></tr>
<tr><td colspan="4">7 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап</td></tr>
<tr><td colspan="4">Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2023 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында бирелгән</td></tr>
<tr><td colspan="4">8 нче бүлек. Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар</td></tr>
<tr><td>№</td><td colspan="3">Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар каралмаган</td></tr>
</table>